КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 август г.Казань № 999

2024 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган Торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибенең 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасындагы авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен 62,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2020 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына бирелә торган торак төзелеше чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен раслау турында» 2020 ел, 31 гыйнвар, 50 нче;

«2021 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен раслау турында» 2021 ел, 14 май, 331 нче;

«2022 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә бер квадрат метр гомуми торак мәйданы кыйммәтен раслау турында» 2022 ел, 14 февраль, 331 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин